КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 декабрь г.Казань № 1150

2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 17 декабрь, 1150 нче
карары белән расланды

2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары нигезендә эшләнгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик культура һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1661 номерлы карары белән расланган «Физик культура һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» федераль проектының күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 159 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында 2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына һәм 2025 һәм 2026 елларда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетларына (алга таба - муниципаль берәмлекләр) концессия килешүләре нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзү (реконструкцияләү) чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен түбәндәге адреслар буенча бирелә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре, Сәйдәшев урамы;

Казан шәһәре, Киров районы, Залесный торак массивы;

Чаллы шәһәре, Габдулла Тукай исемендәге яр буе, 48 йорт.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы нигезендә бирелә.

Субсидияләр бирүне финанс белән тәэмин итү чыганагы - Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан кергән субсидияләр, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчалары.

5. Субсидия түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

а) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары таләпләренә туры килә торган муниципаль хокукый актлары булу;

б) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү йөкләмәсен күздә тота торган субсидия бирү турында килешү төзү һәм әлеге килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык (алга таба - килешү).

6. 2025 елда муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субсидия күләме 383 621,9 мең сум күләмендә билгеләнә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районына - 116 356,4 мең сум;

Казан шәһәренә - 116 356,4 мең сум;

Чаллы шәһәренә - 150 909,1 мең сум.

2026 елда Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субсидия күләме 335 297,2 мең сум күләмендә билгеләнә.

7. Бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгәннән соң, Министрлык муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына субсидия бирүгә заявкалар (алга таба - заявка) кабул итү турында бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша электрон документлар рәвешендә хәбәр җибәрә.

8. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы субсидия алу өчен заявкалар кабул итү турында хәбәр алынган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлыкка электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша электрон документлар рәвешендә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) ирекле формадагы заявканы;

б) финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль берәмлекнең хокукый актыннан өземтә;

в) вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең булуын раслый торган 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль берәмлек бюджеты турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарыннан (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет язмасы) өземтә ;

г) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән концессия килешүенең таныкланган күчермәсен;

д) проект документациясенә һәм мондый проект документациясен әзерләү өчен эшләнгән инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсенең таныкланган күчермәсен.

Заявка муниципаль берәмлек башлыгы яисә аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

Әлеге пунктта күрсәтелгән документлар, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, заявкаларны теркәү журналына кергән көнне Министрлык тарафыннан теркәлә.

9. Әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны аларның комплектлылыгы предметына, аларда булган мәгълүматның тулылыгына, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган шартларга туры килүенә карау һәм субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карарлар кабул итү шушы документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән карар Министрлык тарафыннан боерык рәвешендә кабул ителә.

Кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат Министрлык боерыкны раслаган көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына хәбәр җибәрү юлы белән җиткерелә.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) муниципаль берәмлекнең әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган шартларга туры килмәве;

б) муниципаль берәмлек тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

в) бирелгән мәгълүмат дөрес булмау.

12. Субсидияләр Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып әзерләнә (формалаштырыла) һәм төзелә торган субсидияләр бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен субсидия акчасы исәбеннән финанслашу дәрәҗәсе 99 процент тәшкил итә.

13. Субсидия күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына килешү төзегән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

14. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары финанслашу максатларында субсидия бирелә торган җирле бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченә ирешү турында һәм килешүләрдә билгеләнгән рәвешләр һәм сроклар буенча капиталь төзелеш объектларын проектлау һәм (яисә) төзү (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән, техник яктан яңадан җиһазлау) гамәлләрен башкару графигының үтәлеше хакындагы хисапларны Министрлыкка тапшыралар.

15. Хисап финанс елында субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәсенең хисап чорында план һәм фактта муниципаль берәмлек тарафыннан ирешелгән күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

16. Субсидиядән файдалану нәтиҗәсе булып концессион килешүләр кысаларында төзелгән (реконструкцияләнгән) массакүләм спорт инфраструктурасы объектларының техник әзерлеге дәрәҗәсе тора:

2025 елда:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге объектлары буенча - 100 процент;

Чаллы шәһәре объекты буенча - 30 процент;

2026 елда Чаллы шәһәре объекты буенча - 65 процент.

17. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидиянең максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

18. Хисап финанс елыннан соң килә торган финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидия агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

19. Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

20. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджетка мәҗбүри түләтү чаралары кулланыла.

21. Субсидияләрдән максатчан файдалануны, субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.